ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

**Приказ** **г.Казань** **Боерык**

«12.»12.2019 № 390-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 16.05.2018 ел, 127-од номерлы боерыгы белән расланган Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 16 июнендәге 834 номерлы карары чыгу һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 2 ноябрендәге 310 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында”гы карары үз көчен югалту белән бәйле рәвештә, б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 16.05.2018 ел, 127-од номерлы “Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә

рөхсәтнамә бирүдән тыш,   хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы боерыгы белән расланган(Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән), Федераль  әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш,  хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә) үзгәрешләр кертергә.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис                                                                                    Ф.С.Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 16 маеннан 127-од номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты боерыгының 12.12.2019 елдан 390-од номерлы редакциясендә)

**Федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты, Федераль әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияләрдә булган, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә асрауга һәм үрчетүгә бирелә торган рөхсәтнамәләрдән кала, Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә асрауга һәм үрчетүгә (Россия Федерациясенең кызыл китабына кертелгән, аучылык һәм биологик су байлыкларына кертелмәгән хайваннар дөньясы объектларыннан кала) рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели ( алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: юридик һәм физик затлар, (алга таба – мөрәҗәгать бирүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан күрсәтелә ( алга таба – Комитет).

1.3.1. Комитетның урнашу урыны: Казан, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт.

Комитетның эш вакыты: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 9.00-18.00, җомга 9.00-16.45. Төшке аш 13.00-13.45.

Иҗтимагый транспорт белән “Тинчурин” тукталышына кадәр :
автобуслар № 1, 6, 8, 31, 53, 54, 85, 99, 99 а;
троллейбуслар № 20, 21;
трамвай № 7;
«Ахтямов» тукталышына кадәр:
автобуслар № 5, 23, 56, 68, 72,79.
Бинага керү үткәрү кәгазе яки шәхесне раслый торган документ буенча.
Комитетның район ( районара) бүлекләренең эш тәртибе:
дүшәмбе, пәнҗешәмбе, җомга,шимбә, якшәмбе 9.00-18.00.
Ял көннәре сишәмбе,чәршәмбе
Төшке аш 13.00-13.45.

Гаризаларны кабул итү графигы: дүшәмбе, пәнҗешәмбе, җомга, шимбә, якшәмбе көннәрне Комитетның район (районара) бүлекләренең эш сәгатьләрендә.

1.3.2. Комитетның белешмәләр өчен телефоны: (843) 211-66-94.

1.3.3. Мәгълүмати-телекомммуникатив “Интернет” челтәрендә Комитетның рәсми сайт адресы http://www.ojm.tatar.ru, электрон почта адресы ojm@tatar.ru.

Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәге юллар белән алынырга мөмкин:

1) Комитетның, Комитетның район (районара) бүлекләрендә урнашкан, гариза бирүчеләр белән эшли торган бүлмәсендә куелган, дәүләт хезмәте турында турыдан-туры күреп һәм текстлы мәгълүмат булган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар ярдәмендә;

2) “Интернет” челтәре аша:

Комитетның рәсми сайтында (http://www.ojm.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

3)Комитетка, Комитетның район (районара) бүлекләренә телдән мөрәҗәгать итеп;

4)Комитетка, Комитетның район (районара) бүлекләренә язмача мөрәҗәгать итеп;

1.3.5. Комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы, электрон почтасы, Комитетның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Комитетның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү биналарындагы мәгълүмати стендларда урнаштырылган мәгълүмат, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла һәм үз эченә дәүләт хезмәте турында әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 нче пунктларда күрсәтелгән мәгълүматны ала.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге актлар белән җайга салына:

Россия Федерациясенең Салымнар Кодексы белән (алга таба - РФ СК) ("Российская газета" 07.08.2000 елдан **№** 32, 3340 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

24.04.1995 ел. № 52-ФЗ “ Хайваннар дөньясы турында”гы Федераль закон

белән; (алга таба – № 52-ФЗ Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 24.04.1995, № 17, 1462 ст, кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

27.07.2010 ел. № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон белән (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне истә тотып);

07.05.2012 ел. 601 номерлы “Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында”гы Россия Федерациясе Президенты Боерыгы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты Боерыгы) (Россия Федерациясенең кануннар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Татарстан Республикасы Экология Кодексы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2009, № 1, 5 статья, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

02.11.2010 ел. “Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарының хезмәт күрсәтүләре буенча адмистратив регламентларны эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгешләр кертү турында ”гы 880 номерлы Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының карары (алга таба –ТРМК 880 номерлы карары)(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм Республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46,2144 ст., кертелгән үзгәрешләр белән);

15.12.2017 елдан 996 номерлы “Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турында Кагыйдәнамәне раслау турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары ( алга таба – Комитет турында Кагыйдәнамә) (Татарстан Республикасының кануннар җыентыгы, 2017, № 95, 3544 ст.).

1.5. Бу регламентта киләсе атамалар һәм билгеләмәләр кулланыла:

**хайваннар дөньясы** – Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә яки вакытлыча яши торган һәм табигый азатлыкта булган, ә шулай ук Россия Федерациясенең континенталь шельф табигый байлыкларына һәм икътисади зонасына карый торган барлык төр кыргый хайваннарның тере организмнар барлыгы.

**хайваннар дөньясы объекты** - хайваннар чыгышына караган организм ( кыргый хайван);

**рөхсәтнамә** - урынын һәм вакытын күрсәтеп, билгеле төр хайваннар дөньясы объектларын кулланырга хокук бирә торган, исемле документ.

**ясалма яшәү тирәлеге** –кыргый хайванның яшәешен тәэмин итү өчен кирәкле һәм аның гомеренә һәм сәламәтлегенә куела торган һәвефсезлек таләпләренә, санэпидем- һәм зоологик таләпләргә , ә шулай ук кешенең гомеренә һәм сәламәтлегенә куела торган һәвефсезлек таләпләренә җавап бирә торган, табигый яшәү тирәлегенә якынлашкан ясалма шартлар.

**ярымирекле шартлар** – Татарстан Республикасының табигый объектларында аларны асрау өчен билгеләнгән чикләрдә һәм кыргый хайваннарның яшәешен өлешчә кеше тәэмин итә торган, хайваннарның көченүен чикли торган система.

**техник хата -** дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан ясалган һәм документка кертелгән мәгълүматларның(дәүләт хезмәте нәтиҗәсе), алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документларга тәңгәл килмәвенә китергән **хата**(хәреф

хатасы, грамматик яки арифметик хата).

**дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эш урыны-** Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән "Күп функцияле үзәкләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлегенең кагыйдәләрен раслау турында"гы 1376 нчы карары белән расланган , Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза астында ( алга таба – гариза) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорау күз алдында тотыла (27.07.2010 елдан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 1 пункты). Гариза формасы әлеге Регламентның 1нче кушымтасында бирелгән.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына куела торган таләпнең исеме | Стандартка куела торган таләпнең эчтәлеге | Таләпне яки дәүләт хезмәтен билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәтенең атамасы | Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү (алга таба – Рөхсәтнамә) | № 52-ФЗ Федераль законның 6,26ст. |
| 2.2. Башкарма хакимият органының исеме | Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба - Комитет) | Комитет турында Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1. Рөхсәтнамә (әлеге Регламентның 2нче нче кушымтасында китерелгән форма буенча)<br>2. Рөхсәтнамә бирүне кире кагу турында хат | Комитет турында Нигезләмәнең 4.1.8 п.; 52-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 26 ст. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралса, Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору | Гаризаны теркәгәннән соң 10 көн эчендә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгате көнендә гамәлгә ашырыла. | |

| | |
|---|---|
| вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге,гариза бирүче белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә, аларны күрсәтү тәртибе. | 1. Рөхсәтнамәне алу турында гариза (1нче ку бирелгән форма буенча);<br>2. Вольерның планы (урнашу урыны, чикләре мәйданы);<br>3. Асрау һәм үрчетү проекты (вольерда асрар ителгән, аучылык байлыкларына кермәгән хайв баш санының максималь саны, хайваннарны аш рационы, противоэпизоотик чаралар исемлеге).<br>Дәүләт хезмәтен алыр өчен гариза бланк бирүче шәхси Комитеттан алырга мөмкин.<br>Бланкның электрон формасы Комитетны сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа кушылган документлар, гари белән, кәгазьдә киләсе ысуллар белән тапшыры<br>шәхси (ышанычнамә нигезендә гариза исеменнән эш итүче зат белән);<br>почта аша, алу турында белдерү кәгазе булга хат белән.<br>Документлар, гариза бирүче белән, элек белән расланып, шулай ук электрон рәвештә, "I челтәре мәгълүмат ресурслары яки Республикасының дәүләт һәм муниципаль порталы аша юнәлтелергә мөмкин. |

| | |
|---|---|
| | Шулай ук гариза һәм аңа кушылган док гариза бирүче белән, интернет челтәре аша яки Республикасының дәүләт һәм муниципаль порталы аша, исемен, почта адресын( электрон гариза бирүченең телефон номеры,физик зат фамилиясен, атасының исемен, тору урынын электрон имза белән раслап, электрон тапшырыла ала.<br>Әгәр дә гариза бирүче хокуклы вәкил сыйфа дәүләт хезмәтен алырга вәкаләтле зат сыйфатын очракта, гариза бирүчегә гаризага, вәкаләтләр торган документны да теркәргә кирәк.<br>Шәхси мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук шәхесен раслый торган документ күрсәтелерг |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган кирәкле документларның тулы исемлеге, ә шулай ук гаризачылар белән аларны алу ысуллары, шул санда электрон рәвештә;аларны бирү тәртибе. | Электрон ведомствоара бәйләнеш системас Татарстан Республикасы буенча Федераль хезмәте идарәсеннән алына:<br>1. Юридик затларның Бердәм дәүләт реестр өземтә (гариза бирүче – юридик затлар өчен);<br>2. Шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт рее өземтә (гариза бирүче – шәхси эшмәкәрләр өче Документларны бирү ысуллары һәм алу тәртиб Регламентның 2.5. пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буе пунктта күрсәтелгән документларны, м булганда, электрон формада тапшырырга хоку<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда к документларны тапшырмау, мөрәҗәгать итүчен |

| | |
|---|---|
| | хезмәте күрсәтүдән баш тартуы өчен ниг<br>тормый.<br>Гариза бирүчедән киләсе документлар<br>итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә<br>килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган<br>хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәл<br>каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен док<br>һәм мәгълүмат бирү;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статья<br>өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш<br>Федерациясе норматив хокукый актлары,<br>Республикасы норматив хокукый актлары<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнар<br>дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары<br>дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы<br>карамагында булган дәүләт һәм муниципал<br>күрсәтүләр өчен түләү кертүне раслаучы до<br>һәм мәгълүмат.<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 стать<br>1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклар<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле докум<br>беренчел кабул итүдән баш тартканда яисә дәүл<br>күрсәтүдән баш тартканда аларның булмавы<br>дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм<br>бирү. |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен<br>кирәкле документларны кабул итүдән | Документлар кабул итүдән баш тарту өчен н |

| | |
|---|---|
| баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен каралмаган. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы запросны би һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда торуның максималь вакыты 15 минуттан да ар тиеш. |

| | |
|---|---|
| мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты | Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым катего өчен чират билгеләнмәгән. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте һәм хезмәтләр күрсәтү турында, шул исәптән электрон формада да, соратып алуны теркәү вакыты һәм тәртибе | Гариза кергән көнне.<br>Электрон рәвештә, ял (бәйрәм) көненд мөрәҗәгать, ял (бәйрәм) көненнән соң ки көнендә теркәлә. |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларга керү мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы систем янгын сүндерү системасы, документларны рәсм өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары бел җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урыны тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага к һәм алар чикләрендә күчү уңайлы).Дәүләт хезм күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мул мәгълүматы инвалидларның чикләнгән мөмкин исәпкә алып урнаштырыла. |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге һәм сыйфаты | Дәүләт хезмәтеннән файдалана алу м күрсәткечләре: |

| | |
|---|---|
| күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге , башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә мөрәҗәгать итүчене сайлау буенча (экстерриториаль принцип), Федераль законның 15.1 статьясында каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратып алу юлы белән (комплекслы запрос ) | Комитет биналарының җәмәгать тран үтемлелек зонасында урнашуы;<br>кирәкле белгечләр саны, шулай ук бирүчеләрдән документлар кабул ителәә торган булу;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган б инвалидлар өчен уңайлы итү;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәтт күрсәтүгә комачаулаучы башка киртәләрне жин ярдәм күрсәтү;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» че Комитетның рәсми сайтында дәүләт хезмәте к ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы м булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрс булып түбәндәгеләр тора:<br>документларны кабул итү һәм карап срокларын үтәү;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>Комитет белгечләре тарафыннан дәүләт күрсәтү барышында бу регламентны бозу нигезле шикаятьләр булмау;<br>гариза бирүченең Комитет белгечләре белә саны:<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле докум шәхси тапшырганда - ике тапкырдан д (консультацияләрне санамыйча) ;<br>-дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле докум |

| | |
|---|---|
| | почта аша яки электрон рәвештә тапшырганда – артмау.<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза б Комитет (бүлек)яки КФУ белгече белән хезм дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул санда дәүләт күрсәтү өчен гариза бирү күп функцияле үзәк, а ераклашкан эш урыны аша гамәлгә ашырылмый<br>Экстерриториаль принцип буенча яки компл соратып алу составында дәүләт хезмәте күрсәте<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан К шәхси мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча бирелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация телефон аша шәхси яки элект формасында электрон почта аша (e-mail: ojm Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең порталындагы Интернет-кабул итү бүлмә http://ojm.tatarstan.ru) бирелергә мөмкин.<br>Гаризаны һәм документларны гомуми файда мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре а исәптән «Интернет» мәгълумати-телекомм челтәре аша бирү мөмкинлеге бар. |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү;

рөхсәтнамә яки баш тарту турында хат әзерләү;

гариза бирүчегә рөхсәтнамә яки баш тарту турында хат бирү;

техник хатаны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, шул санда гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны тутыруда булышу.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алырга дип, шәхси, телефоннан һәм (яки) электрон почта аша, Бүлеккә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече, гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итү формасы һәм башка мәсьәләләр буенча. Кирәк булган очракта Бүлек белгече документларны тутырырга булыша.

Бу пунктта каралган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, документларны тутыру өлешендә булышлык.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхси, почта аша, электрон почта аша, Татарстан Республика Хөкүмәтенең Интернет-кабул итү бүлмәсе аша, Комитетка дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

3.3.2. Бүлек белгече:

гаризаны кабул итә һәм терки;

гариза бирүче, хокуклы вәкил сыйфатында яки дәүләт хезмәтен алырга вәкаләтле зат сыйфатында килгән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

гаризаны гариза бирүчегә тапшыра яки почта аша, документларны кабул итү вакытын, теркәү номерын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен җибәрә.

Бу пунктта билгеләнгән процедуралар гариза биргән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен,кабул ителгән һәм теркәлгән документлар.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон аралашу

системасы ярдәмендә Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә электрон рәвештә түбәндәге документларны соратып запрослар җибәрә:

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (мөрәҗәгать итүчеләр-юридик затлар өчен);

бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә (гариза бирүчеләр өчен - шәхси эшмәкәрләр өчен).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запросларны формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгечләре ведомствоара электрон аралашу системасы аша кергән запрослар нигезендә билгеләнгән срокта соратып алына торган документларны (белешмәләрне) тапшыралар.

Процедураларның нәтиҗәсе: сорауларга җавап бирү, яки соратып алына торган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Рөхсәтнамәне яки баш тарту турында хатны әзерләү.

3.5.1. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчедән һәм Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән кергән документлар нигезендә:

әлеге регламентның 2.5 пункты таләпләренә туры килү-килмәүне тикшерә;

рөхсәтнамәне тутыра яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хат әзерли;

тутырылган рөхсәтнамәне яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хатны Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентта каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рөхсәт яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында Бүлек башлыгына килешүгә җибәрелгән хат.

3.5.2. Бүлек башлыгы рөхсәтнамәне яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хатны килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имза куярга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге Регламентта каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имза салу өчен Комитет рәисенә җибәрелгән Рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хат.

3.5.3. Комитет рәисе рөхсәтнамәгә яисә рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турындагы хатка кул куя һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура әлеге регламентта каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имза куелган Рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хат.

3.6. Рөхсәтнамәне яки баш тарту турында хатны бирү

3.6.1. Бүлек белгече Рөхсәтнамәне яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турында хатны терки һәм гариза бирүчегә хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турындагы хатка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән Рөхсәтнамә яки гариза бирүчегә рөхсәтнамә

бирүдән баш тарту турында җибәрелгән хат.

3.6.2. Бүлек белгече гариза бирүчегә яисә аның ышанычлы затына (ышаныч кәгазе булган очракта) рөхсәтнамә бирә һәм реестрга бирелгән Рөхсәтнамә турында мәгълүматлар кертә (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Рөхсәтнамә яки рөхсәтнамә бирүдән баш тарту турындагы хатка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән Рөхсәтнамә.

3.7.Техник хатаны төзәтү.

Рөхсәтнамәне яңадан ясау, гариза бирүчегә бирелгән Рөхсәтнамәдә кертелгән техник хаталарны бетерү белән бәйле рәвештә башкарыла.

Рөхсәтнамәне яңадан ясау, гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы Рөхсәтнамә теркәлгән гариза (тәкъдим ителгән форма әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән) нигезендә башкарыла.

3.8.1. Бүлек белгече түбәндәге гамәлләр башкара:

гаризалар кабул итү һәм теркәү;

гариза бирүчегә шәхси яки почта аша яисә электрон почта аша (аның теләге буенча) керә торган номерын билгеләп, документларны кабул итү датасы турында тамга белән, гариза күчермәсен тапшыру.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза.

3.7.2. Бүлек белгече:

Рөхсәтнамәне яңадан ясый;

Рөхсәтнамәне яңадан ясау турында гариза бирүчегә хат проектын әзерли һәм Бүлек башлыгына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченә гариза җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән өземтә.

3.7.3. Бүлек башлыгы әзерләнгән Рөхсәтнамәнең дөреслеген тикшерә, хат проектын килештерә һәм аларны Комитет рәисенә имза куярга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, Рөхсәтнамә һәм хат проекты Бүлек башлыгына килешүгә кергән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кул куюга юнәлдерелгән Рөхсәтнамә һәм хат проекты.

3.7.4. Комитет рәисе хат проектына һәм аңа кушып бирелә торган Рөхсәтнамәгә кул куя һәм Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Бүлек башлыгыннан хат проекты кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килешенгән хат проекты, Рөхсәтнамә.

3.7.5. Бүлек белгече, Рөхсәтнамә белән бергә гариза бирүчегә яки аның ышанычлы затына (ышанычнамәсе булган очракта) имза астына, бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы хатны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче яки аның

ышанычлы заты килгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән хат һәм техник хатасы төзәтелгән Рөхсәтнамә.

### 4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшерү формалары һәм тәртибе

4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен, шулай ук җаваплы затлар тарафыннан карарлар кабул ителүне агымдагы контрольдә тоту Бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү, тикшерүләр уздыруны, урындагы затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьле гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләрен карау, алар буенча карар кабул итүне һәм җавап әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларны үтәүне саклау артыннан тикшерү формалары:

эш башкаруны алып бару;

каралган документларның нәтиҗәсе закон таләпләренә туры килүе (әлеге Регламентның);

документларны кабул итү вакытын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, аның нәтиҗәсен бирү вакытын һәм тәртибен саклау.

Тикшерүләрне уздыруның кабатлануы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) характер йөртә.

4.2.Тикшерүләрне уздыру нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыклаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар, законнар белән каралган тәртиптә, җаваплылыкка тарттырылалар.

4.4 Гариза бирүчеләр ягыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү артыннан тикшерү,

Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольдә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Комитетныэ ачык эшчәнлегендә, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алганда һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлегендә гамәлгә ашырыла.

### 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, ә шулай ук аларның вазыйфаи затларының һәм дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Бүлек белгече, Бүлек башлыгы, Комитетның район хезмәткәрләре гамәлләрен (гамьсезлеген) судка кадәрге тәртиптә, Комитет рәисенә шикаять кылу хокукына ия.

Комитет рәисе белән кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамьсезлегенә)

шикаять Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогы бозылу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы бозылу;

3)дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп итү;

4)гариза бирүчедән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тартуның нигезләре федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәргән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын һәм тәртибен бозу;

9) әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул иткән вакытта документларның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документларны яисә мәгълүматларны таләп итү яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

5.3. Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталы аша, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.4.Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

Комитетның исеме, гамәлләренә (гамьсезленегә) шикаять бирелә торган, Комитетның дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи заты, дәүләт хезмәткәре исеме, фамилиясе, атасының исеме;

гариза бирүче-физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, гариза бирүче –юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, һәм шулай ук гаризачыга җавап бирү өчен

элемтә телефонының номеры (номерлары), (булган очракта) электрон почта һәм почта адресы (адреслары);

Комитет, аның вазыйфаи затының шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;

мөрәҗәгать итүче алар нигезендә Комитетның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәл кылмавы (гамәл кылмавы) белән килешмәгән дәлилләре.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслаучы документлар (булганда) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы - аны теркәгәннән соң 15 эш көне эчендә. Комитет, Комитетның вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканга шикаять белдергән очракта яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогы бозылганда -аны теркәгән көннән биш эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1)шикаять, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны кире кагу, җибәрелгән хаталарны төзәтү, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм җитешсезлекләрне төзәтү, аларны алу Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары белән каралмаган акча чараларын гаризачыга кайтарып бирү формасында канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип тану очрагында, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүчегә киләчәк гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип тану очрагында мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәсендә административ хокук бозылу яисә җинаять кылу билгеләре ачыкланса, шикаятьне карау вәкаләтләре белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат кичекмәстән бар булган материалларны прокуратура органнарына юнәлтә.

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитеты рәисенә

__________________________________
(Ф.И.О.)

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә алу өчен гариза

__________________________________________________________________________
(атамасы (тулы һәм кыска), оештыру-хокукый формасы, юридик затның урнашу урыны яки шәхси эшмәкәрнең ( физик затның) исеме, фамилиясе, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары )

Түбәндәге төр аучылык байлыкларына һәм биологик су ресурсларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма булдырылган яшәү тирәлегендә асрауга һәм үрчетүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм:

__________________________________________________________________________

максат:___________________________________________________________________

(хайваннар дөньясы объектларын асрау һәм үрчетү эчтәлегенә кагылышлы эшчәнлек төрләре һәм максатлары күрсәтелә (хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегендә урнаштыру (һәм) яки сату)

Асрау шартлары: ___________________________________________________________

(ярымирекле асрау өчен куллана торган территориянең чикләре һәм мәйданы, объектларның тасфирламасы һәм адресы)

Хайваннар дөньясы объектларын заказ бирүчегә алып бару шартлары яки яшәү тирәлегендә урнаштыру ____________________________________________________

( транспорт төре,яшәү тирәсенә урнаштырырга җыенган хайваннар дөньясы объектларының саны)

Хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегендә урнаштыру тәртибе

_________________________________________________________________________

(табигый яшәү тирәлегенә чыгарырга җыенган хайваннар дөньясы объектларының саны һәм төре, чыгару вакыты )

____________________________________________________ ____________

(юридик зат җитәкчесенең фамилиясе, инициаллары (шәхси эшмәкәрнең)) (имза)

«___»_________ 20___ ел

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм

«___»_________ 20___ ел ____________

(имза)

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

____________________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының исеме, адресы)

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә

**Рөхсәтнамә**

Серия ___________ № __________

______________________________________________________________ бирелде.
(атамасы (тулы һәм кыска), оештыру-хокукый формасы, юридик затның урнашу урыны яки шәхси эшмәкәрнең исеме, фамилиясе, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары )

Эш төре: (ярым ирекле шартларда, ясалма яшәү тирәлегендә асрау һәм(яки)үрчетү)
______________________________________________________________________
(кирәклесен күрсәтергә)

Хайваннар дөньясы объектлары: _____________________________________________
______________________________________________________________________
(аучылык байлыкларының русча һәм латинча атамалары, асрарга һәм үрчетергә планнаштырылган баш һәм җенес саны)

максат: _______________________________________________________________
(максатны күрсәтергә)

Асрау шартлары:

________________________________________________________________________

(ярымирекле асрау өчен куллана торган территориянең чикләре һәм мәйданы, объектларның тасвирламасы һәм адресы)

Хайваннар дөньясы объектларын заказ бирүчегә алып бару шартлары яки яшәү тирәлегендә урнаштыру

________________________________________________________________________

( транспорт төре,яшәү тирәсенә урнаштырырга җыенган хайваннар дөньясы объектларының саны)

Хайваннар дөньясы объектларын яшәү тирәлегендә урнаштыру тәртибе

________________________________________________________________________

(табигый яшәү тирәлегенә чыгарырга җыенган хайваннар дөньясы объектларының саны һәм төре, чыгару вакыты )

Рөхсәтнамәнең юридик көче: "___"______ 20__ елдан "___"_____ 20__ елга кадәр.
Рөхсәтнамәне бирде ______________________________________________

(рөхсәтнамә биргән вазыйфаи затның фамилиясе , ициаллары)

_______________________ __________________

(имза) (Ф.И.О.)

Рөхсәтнамәне бирү вакыты "___"_________ 20__ ел.
П.У.

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризлыгымна бирәм.**

"___"__________ 20____ ел __________________

(имза)

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү реестры

| № п/п | Рөхсәтнамә алган зат турында мәгълүматлар | Аучылык байлыкларын асрау төре (ярым ирекле шартларда яки ясалма яшәү тирәлегендә) | Асрау һәм үрчетү өчен рөхсәтнамә бирелгән , аулау объетларына кертелмәгән, хайваннар дөньясы | Баш саны һәм аларның җенес катнашм | Асрау һәм үрчетү максаты | Асрау шартлары ярымирекле асрау өчен куллана торган | Рөхсәтнамәнең бирелү вакыты, сериясе, номеры | Рөхсәтнамәнең гамәлдә булу срогы | Рөхсәтнамәне гамәлдән чыгару өчен | Рөхсәтнамәне гамәлдән чыгару турындагы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | объектлары төрләренең русча һәм латинча атамасы | асы | | территориянең чикләре һәм мәйданы, объектларның тасфирламасы һәм адресы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | |
| | | | | | | | |

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

_______________________________________
(Ф.И.О.)

_____________________________________
(физик затлар өчен: Ф.И.О.,
адрес (почта һәм(яки)электрон)

_______________________________________
Юридик затлар өчен: оешманың исеме, адрес (почта һәм(яки)электрон)

**Техник хатаны төзәтү турында гариза.**

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

________________________________________________________________________
(бирелгән документ)

______________________________________________________________курсәтелгән.

Дөрес мәгълүматлар:
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булып килгән документны төзегәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм ул үзгәрешләрне документка кертүегезне сорыйм.

Киләсе документларны терким:
1. ____________________________________________________________
2.____________________________________________________________

Документның әзерлеге турында хәбәр итүегезне сорыйм.

________________________________________________________________________________
(хәбәр итү ысулы)

"___"__________ 20___ ел                ________________  (________________________)
(гариза бирүченең имзасы)      (имзаны чишү)

Федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигый территорияләрдә торучы хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирүдән тыш, хайваннар дөньясы объектларын (Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш) ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә тотуга һәм үрчетүгә рөхсәтнамә бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә өчен)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Комитет башлыгы | 211-66-99 | Fjodor.Batkov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | 211-70-78 | Ilfat.Valeev@tatar.ru |
| Бүлек белгечләре | 211-70-78 | Anna.Mironova@tatar.ru |
| | | Mariya.Ushakova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Җир асты байлыкларын, табигый байлыкларны куллану һәм тирә якны саклау сораулары буенча бүлек башлыгы | 264-77-78 | Marat.Fashutdinov@tatar.ru |